**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**муниципального**
**образования « Масягутовского**
**сельского поселения»**
ул. Дружба д.12
с. Масягутово, Азнакаевский район, 423311
Тел ( Факс) : (8 – 85592) 38-2-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**“ Мәсгут авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге**
**БАШЛЫГЫ**
Дружба урамы, йорт12, Мэсгут авылы,
Азнакай районы,423321
Тел(факс) :(8 –85592) 38-2-16

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«10 » ноябрь 2020 ел № 23

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 22 ноябренә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауларны расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум куләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Яхшы-Бай авылы зиратын коймалау.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык: Э.Ә.Габдрахманов

